КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 4 май г.Казань № 413

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2017 ел, 26 апрель, 252 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президентының «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме турында» 2022 елның 12 апрелендәге ПУ-266 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2017 ел, 26 апрель, 252 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 14 июнь, 479 нчы; 2020 ел, 11 февраль, 97 нче һәм 2020 ел, 14 декабрь, 1137 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре һәм 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә ирешүгә шактый зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге турындагы истәлекне мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия төзү турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән күренекле эшлеклеләре һәм 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә ирешүгә шактый зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт батырлыгы

һәм фидакарьлеге турындагы истәлекне мәңгеләштерү эшчәнлеген җайга салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта татар текстында «күренекле эшлеклеләре» сүзләреннән соң «һәм 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә ирешүгә шактый зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге турындагы» сүзләрен өстәргә, «истәлеген» сүзен «истәлекне» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктта «Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре һәм 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә ирешүгә шактый зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге турындагы истәлекне мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә»;

1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре һәм 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә ирешүгә шактый зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге турындагы истәлекне мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Комиссия) Татарстан Республикасын үстерүгә зур өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре (алга таба – Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре) истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләрен хәл итүнең бердәм тәртибен билгеләү, шулай ук 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә ирешүгә шактый зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге турындагы истәлекне мәңгеләштерү мәсьәләләрен карап тикшерү юлы белән хәрби-тарихи һәм хезмәт мирасын саклап калу максаты белән төзелде.

2. Комиссия Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар, предприятиеләр коллективлары, гражданнар тарафыннан кертелгән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү турындагы үтенечнамәләрне карап тикшерү һәм Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча материаллар әзерләү, шулай ук «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941 – 1945 еллар» республика исемен бирү турындагы үтенечнамәләрне карап тикшерү һәм тиешле карарлар әзерләү мәсьәләләре буенча даими эшләүче консультатив орган булып тора.»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Комиссия түбәндәге мәсьәләләрне карап тикшерә:

4.1. Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген түбәндәге формаларда мәңгеләштерү:

Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерә торган һәйкәлләр (бюстлар), стелалар, обелисклар, мемориаль такталар, истәлекле билгеләр, башка мемориаль корылмалар һәм объектлар урнаштыру;

Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре исемнәрен торак пунктлар территориясендәге физик-географик объектларга, урамнарга һәм мәйданнарга, проспектларга һәм аллеяларга, башка шәһәр төзү объектларына, оешмаларга (шул исәптән мәгариф оешмаларына), шулай ук Татарстан Республикасында үткәрелә торган чараларга (фестивальләргә, конкурсларга, спорт ярышларына һ.б.) бирү;

Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләренә багышланган мемориаль музейлар төзү, күргәзмәләр оештыру;

4.2. 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә ирешүгә шактый зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге турындагы истәлекне мәңгеләштерү.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Комиссиянең төп бурычлары:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар, предприятиеләр коллективлары, гражданнар тарафыннан кертелгән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү турындагы үтенечнамәләрне карап тикшерү һәм Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча материаллар әзерләү;

Татарстан Республикасы Президентының «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941 – 1945 еллар» республика исеме турында» 2022 елның 12 апрелендәге ПУ-266 номерлы Указы нигезендә «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941 – 1945 еллар» республика исемен бирү турындагы үтенечнамәләрне карап тикшерү»;

Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре һәм 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә ирешүгә шактый зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге турындагы истәлекне мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар, учреждениеләр хезмәттәшлеген оештыру һәм аларның килешенгән гамәлләрен тәэмин итү;

ведомствоара чаралар оештыру;

Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерүгә бәйле эшчәнлекне хокукый җайга салуны камилләштерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләү.»;

6 пунктның дүртенче абзацында «истәлеген мәңгеләштерү» сүзләреннән соң «һәм хәрби-тарихи, хезмәт мирасын саклап калу, 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә ирешүгә шактый зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге турындагы истәлекне мәңгеләштерү» сүзләрен өстәргә;

10 пунктта «кварталга 1 тапкыр» сүзләреннән соң «очрашып яки читтән торып» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта «Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре» сүзләреннән соң «һәм 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә ирешүгә шактый зур өлеш керткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт батырлыгы һәм фидакарьлеге турындагы» сүзләрен өстәргә, «истәлеген» сүзен «истәлекне» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин